РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

«25» октября 2022г. с. Тюлячи № 215

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 22 апрелендәге 263 номерлы « Теләче муниципаль районы бюджет өлкәсендә хезмәт хакы түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмаган бюджет өлкәсендәге аерым оешмаларда эшләүчеләрнең хезмәт хакларын түләү шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2022 елнын 17 сентябрендәге 1013 номерлы «Бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалар хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен күтәрү һәм «Бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет даирәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә һәм Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренә түләүне тәртипкә китерү максатларында, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елнын 22 апрелендәге 263 номерлы « Теләче муниципаль районы бюджет өлкәсендә хезмәт хакы түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган бюджет өлкәсендәге аерым оешмаларда эшләүчеләрнең хезмәт хакларын түләү шартлары турында» карарына (12.10.2020 № 439, 02.03.2022 № 30, 29.09.2022 № 185 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә,

1.1. Карарның 1 пунктының өченче абзацын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«- аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре муниципаль берәмлекләрдә аерым бюджет өлкәсен оештыруның структур бүлекчәсе җитәкчесенең вазыйфаи оклады буенча берничә мәртәбә исәпләп чыгарыла,

аларга Теләче муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый, ул 12 688 сум тәшкил итә;».

1.2. Карарның 3 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«3) Вазыйфаи окладның 15 проценты күләмендә айлык акчалата бүләкләү.».

1.3. Карарның 7 пунктының 4 пунктчасын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«4) Айлык акчалата бүләкләүне - вазыйфаи окладларның 15 проценты күләмендә.».

2. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Җитәкче И. Х. Хәмидуллин